Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**

**карары**

**« 28 » декабрь 2015 ел** **№ 18**

**«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге урамнарга исемнәр бирү турында**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 07.12.2005 ел, № 116-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең топонимика комиссиясе турында Арча шәһәр Советының 18.12.2015 ел, № 15 карары нигезендә, тарихи шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү максатларында, ачык шәхес сыйфатлары, татар мәдәниятенә һәм әдәбиятына зур өлеш керткәне өчен, Арча шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Васильева Божа авылындагы яңа урамнарга түбәндәге исемнәрне бирергә:

- "Радик Фәизов»;
- "Фәрваз Миңнуллин».

2. Арча шәһәре Башкарма комитетына бер ай вакыт эчендә йөкләргә:

- Арча шәһәре муниципаль берәмлеге урамнары исемнәре реестрына яңа төзелгән урамнар исемен кертергә;
- яңа урамнарда адреслы атрибутика урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе — И.Г.Нуриев